ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ИСКЕ ДӨРЕШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

КАРАР

«03» апрель 2024 ел                    Иске Дөреш авылы                    № 10

**«Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Иске Дөреш авыл җирлеге составына керүче Таулы Дөреш авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 17 октябрендәге 1 номерлы гражданнар җыены карарына һәм 2023 елның 17 октябрендәге 2 номерлы Тукай муниципаль районы Иске Дөреш авыл җирлеге Таулы Дөреш авылында гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Иске Дөреш авыл җирлеге Таулы Дөреш авылында гражданнар җыенын билгеләү хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Тукай муниципаль районы «Иске Дөреш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставы, «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының Иске Дөреш авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында» нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Иске Дөреш авыл җирлеге Советының 2019 елның 31 октябрендәге 8/1 номерлы карары нигезендә

**КАРАР БИРӘМ:**

1. «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Иске Дөреш авыл җирлеге составына керүче Таулы Дөреш авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 17 октябрендәге 1 номерлы гражданнар җыены карарына һәм 2023 елның 17 октябрендәге 2 номерлы Тукай муниципаль районы Иске Дөреш авыл җирлеге Таулы Дөреш авылында гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча 2024 елның 16 апреленә 11.00 сәгатькә гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез үзгәрешләр кертергә ризамы:

1) түбәндәге редакциядә бәян итеп, гражданнар җыенына чыгарылган һәм кабул ителгән «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Иске Дөреш авыл җирлеге составына керүче Таулы Дөреш авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 17 октябрендәге 1 номерлы гражданнар җыены карарына:

«-торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле билгеләнештәге автомобиль юллары составына керми торган җәяүлеләр

куперләрен һәм юлүткәргечләрне, җәяүлеләр җир өсте кичүләрен ремонтлау (куперне һәм чишмәгә юлны ремонтлау);

2) түбәндәге редакциядә бәян итеп, 2023 елның 17 октябрендәге 2 номерлы Тукай муниципаль районы Иске Дөреш авыл җирлеге Таулы Дөреш авылында гражданнар җыены карарына:

«-торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле билгеләнештәге автомобиль юллары составына керми торган җәяүлеләр куперләрен һәм юлүткәргечләрне, җәяүлеләр җир өсте кичүләрен ремонтлау (куперне һәм чишмәгә юлны ремонтлау)

«ӘЙЕ» «ЮК»

3. Гражданнар җыенын түбәндәге адрес буенча үткәрергә: Татарстан Республикасы, Тукай муниципаль районы, Иске Дөреш авыл җирлеге, Таулы Дөреш авылы, Ленин ур., 52/2 йорт.

4. Халык җыенын оештыручы итеп Татарстан Республикасы, Тукай муниципаль районы Иске Дөреш авыл җирлеге Башкарма комитетын билгеләргә.

5. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Иске Дөреш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставы нигезендә махсус мәгълүмат стендларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының рәсми сайтында (tukay.tatarsatan.ru) урнаштырырга.

6. Әлеге карар халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Тукай муниципаль районы
Иске Дөреш авыл җирлеге Башлыгы Р.М. Дусадбеков